# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# КАРАР

20.11.2017 № 85

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә 20 ноябрь 2017 елда 19 ноябрь 2017 елда узган җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 900 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-631, бу 70,11% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 617 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 97,78% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 11 кеше тавыш бирде, бу 1,74% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

"2017 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

– авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, Кәче авылында, Тау өсте, Тау итәге урамындагы автомобиль юл-урам челтәреннән вак таш сатып алу,нигез һәм юл өслеге салу буенча хезмәт күрсәтү.,

- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

Якты Кен авылында 3 данә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми

сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе рәисе | Б. И. Кадыйров |
| Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе секретаре | Л. И. Нурмиева |